ГЛАВА ОКТЯБРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

17.11.2021 — 06

пос. Октябрьский

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең Яңа Болгар авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Уставынаың 24 ст. туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2021 елның 27 ноябренә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Яңа Болгар авылы гражданнарының үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
   " Сез 2022 нче елда Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Яңа Болгар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме:
   - Яңа Болгар авылында су белән тәэмин итү системаларын төзү һәм ремонтлау
   - Зират территориясен төзекләндерү

   «ӘЙЕ» «ЮК»
3. Яңа Болгар авыл клубы бинасында халык җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Яңа Болгар авылы, Школьная урамы, 42 йорт, 11.00 сәгатьтә.
4. Халык җыенын оештыручы итеп Октябрьский авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә .
5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы Ш. Р. Азизов